| | | |
|---|---|---|
| **ГЛАВА ЮРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 30 28.10.2024 ел

**2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең Юртау торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлеге Уставының 14 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Юртау авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. 08.11.2024 елның 14.00 сәгатенә түбәндәге адрес буенча урнашкан Юртау авыл клубы бинасында : Татарстан Республикасы, Минзәлә муниципаль районы, Юртау т. п., Урман ур., 2 й. Татарстан Республикасы Минзәлә районы Юртау авыл җирлегенең юрта торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында тәкъдим ителгән сорауларны расларга:

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

2.1. Йорт торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Дорожная, Взлетная, Л.П. Пермяков урамнарының төньягыннан керү юлларны вак таш белән каплау вак таш салу, эш өчен шартнамә буенча түләү);

2.2. 2) Юртау торак пункты территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территориядә үләнне чаптыру, ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)?».

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Юртау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юртау авыл җирлеге башлыгы И.Ю.Кадыров